КУЛЬТУРА МИНИСТРЛЫГЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЛАР

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.11.2020 г. Казань № 837 од

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасарына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтен күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянырга.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 10 сентябрендәге 729 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестрына кертү өчен Регламентны билгеләнгән тәртиптә җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Ю.И.Әдһәмовка йөкләргә.

**Министр** **И.Х.Әюпова**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2020 елның 18 ноябрендәге
837 од номерлы боерыгы
белән расланды

# Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы Федераль законның 2 статьясындагы 2.2 пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар (алга таба – гариза бирүче, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33 йорт.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш 12.00 дән 12.45 кә кадәр.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризалар дүшәмбе – пәнҗешәмбе көннәрендә 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга көнне 9.00 дән 16.45 кә кадәр кабул ителә, төшке аш 12.00 дән 12.45 кә кадәр.

Җәмәгать транспорты белән «Ирек мәйданы» тукталышына кадәр бару:

10а, 22, 28, 28 а, 30, 35, 54, 63, 70, 89, 91 номерлы автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар.

Бинага керү өчен рөхсәтнамә яки шәхесне раслый торган документ күрсәтергә кирәк.

1.3.2. Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә өчен телефоннары: (843) 264-74-38; (843) 264-74-73, (843) 264-73-91, (843) 264-73-98.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтының адресы: http://mincult.tatarstan.ru, электрон почта адресы: mkrt@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге чыганаклардан алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат язылган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язма рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, рәсми сайты адресы, шулай ук электрон почтасы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында (https://mincult.tatarstan.ru/) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында һәм Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гариза бирүче – дәүләт хезмәтен күрсәтү турында телдән, язмача яисә электрон формада бирелгән гариза белән мөрәҗәгать иткән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма (аларның вәкаләтле вәкилләре);

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы бәяләмәдә күрсәтелгән, яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилле хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавына китергән хата (ялгыш язу, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Башка төшенчәләр һәм терминнар 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә кулланыла.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куелган таләпнең аталышы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Күрсәтелә торган хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында»гы карарының (алга таба – 681 номерлы карар) 2 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы |

| | | |
|---|---|---|
| | | коммерцияле булмаган оешмалар реестры турында»гы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручы дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр),<br>681 номерлы карарның 2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Әлеге Регламентның 2 номерлы кушымтасындагы форма буенча язылган бәяләмә яки әлеге Регламентның 3 номерлы кушымтасы нигезендә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә | Кагыйдәләрнең 5, 7, 8 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору | Бәяләмә бирү турындагы гариза теркәлгән көннән соң 10 эш көне дәвамында.<br>Министрлык Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә запрос җибәргән очракта, әлеге срок озайтылырга, әмма 15 эш көненнән дә артык булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.<br>Әлеге карарны кабул итү вакытын озайту турында Министрлык гариза бирүчегә гариза кергән көннән алып биш эш көне эчендә хәбәр итә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору Россия | Кагыйдәләрнең 6, 9 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| вакыты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Федерациясе законнарында каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан (почта буенча, электрон адреска, факс буенча) файдаланып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү Татарстан Республикасы мәдәният министры тарафыннан бәяләмә (бәяләмәне бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) имзаланган көннән соң бер эш көне эчендә башкарыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен таләп ителгән, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтләре күрсәтү ысуллары, шул исәптән электрон формада күрсәтү | а) әлеге Регламентның 1 номерлы кушымтасындагы форма буенча тутырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза);<br>б) гариза бирүченең гамәлгә кую турындагы документлары күчермәләре;<br>в) гариза бирүче исеменнән аның вәкиле документлар тапшырган очракта, гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкару өчен кирәкле, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләренраслый торган ышанычнамә.<br>Гаризага оешма күрсәтә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, характеристикалар, эксперт бәяләмәләре, кызыксынучы органнар каршындагы | Кагыйдәләрнең 5 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| ысуллары, аларны күрсәтү тәртибе | иҗтимагый советлар бәяләмәләре, дипломнар, рәхмәт хатлары күчермәләре һәм башкалар) беркетелә ала.<br>Гариза бирүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәтләр буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән очракта, гариза бирүче күрсәтә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүченең аларны тапшырырга хокукы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә коммерцияле булмаган оешманың гариза бирер алдыннан узган ике ел эчендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавы турында белешмәләр алына (Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе).<br>Гариза бирүче үз теләге белән әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырырга, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон формада тапшырырга хокуклы. | Кагыйдәләрнең 6 пункты,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны кабул итү ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру каралмаган документларны тапшыру яки башкару каралмаган гамәлләрне башкару;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерация норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яки) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документлар һәм мәгълүматлар, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы докуменлар һәм мәгълүматлар тапшыру;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, | хакында»гы карары (алга таба – 880 номерлы карар) |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны тапшыру | |
| 2.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге | Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында санап үтелгән документлар тапшырылмаган | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (күрсәтелә торган хезмәтнең күләме, сроклары, сыйфаты) туры килмәве;<br>б) иҗтимагый файдалы хезмәтне башкаруда турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы, тиешле квалификациясе булган затларның саны җитмәве;<br>в) бәяләмә бирелгәнче узган ике ел дәвамында оешманың суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль | Кагыйдәләрнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | күзәтчелек органнары, компетенцияләре буенча башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип табылган, иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына карата шикаятьләр булу;<br>г) оешма турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем алырлык булуы дәрәҗәсенең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булса) туры килмәве;<br>д) бәяләмә бирелгәнче узган ике ел дәвамында оешманың күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләре буенча 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында намуссыз тәэминатчылар реестрында торуы турында мәгълүмат булу;<br>е) дөрес булмаган белешмәләр булган документлар яисә тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документлар тапшыру.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, әлеге хезмәтне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма | Гариза бирүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтүне) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алуны көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында»гы Указының 1 пунктындагы «д» пунктчасы |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гаризасын теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза кергән көнне.<br>Гариза ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның | 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»гы Федераль закон,<br>880 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектлардан инвалидлар файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр | чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Бинаның, бүлмәләрнең һәм хезмәтләрең инвалидлар, шул исәптән кресло-коляскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү чаралары күрелә, шул исәптән:<br>Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә тоткарлыксыз кереп йөрү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык булу өчен шартлар;<br>Министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына шул исәптән кресло-коляска файдаланып утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләрендә зур тайпылышлар булган инвалидларны озатып йөрү һәм Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә аларга ярдәм итү;<br>чикләнгән тормыш эшчәнлеген исәпкә алып, инвалидларның бинага, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү өчен җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;<br>инвалидларга кирәкле авазлы һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы | |

| | | |
|---|---|---|
| | Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр ярдәмендә кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче файдалану;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы «Озата йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»гы боерыгы белән расланган формада һәм тәртиптә озата йөрүче этне махсус укытуны раслаучы документ булганда, мондый этне Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрне башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең вазифаи затлар белән үзара аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:<br>биналарның җәмәгать транспортына якын урында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен уңайлы булуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат-коммуникация технологияләрен дә кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган запрос бирү юлы белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче теләге буенча башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә файдалану) мөмкинлеге яки | мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон формада гариза бирү мөмкинлеге;<br>гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада алу мөмкинлеге;<br>инвалидларның бүлмәләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган, хезмәтләрдән башкалар белән беррәттән файдаланырга комачаулаучы башка каршылыкларны җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозу прецедентларының (аларга карата нигезле шикаятьләрнең) булмавы.<br>Гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара аралашулары саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча); | |

| | | |
|---|---|---|
| мөмкин түгеллеге | дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә аралашуы дәвамлылыгы 15 минуттан артмый. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынында башкарылмый. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mincult.tatarstan.ru сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча башкарылмый | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында»гы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелган электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | 63-ФЗ номерлы Федераль закон<br>210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган башка таләпләр | | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешен дә кертеп, гариза бирүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар төзү һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә әзерләү;

5) гариза бирүчегә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә бирү;

6) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыруны да кертеп, гариза бирүчегә консультация бирү, аңа ярдәм итү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта (шул исәптән электрон почта) аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, гариза бирүче яза торган гариза формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләрен дә кертеп, консультация бирә. Кирәк булганда Бүлек белгече, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру өлешен дә кертеп, гариза бирүчегә ярдәм итә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән мөрәҗәгатьләрдән тыш, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация, искәрмәләр, гариза бирүчегә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру өлешен дә кертеп, ярдәм итү, гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында консультация бирү (гариза бирүчегә ярдәм итү) турында язма.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән Министрлыкның контроль һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – Эш башкару бүлеге) гариза бирә.

Гариза заказлы хат белән почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм гомуми

файдаланудагы электрон чыганаклардан һәм (яисә) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, «Интернет» челтәрен дә кертеп, тапшырыла.

Гариза шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

Заказлы хат белән почта аша яисә электрон формада тапшырылган гариза гомуми тәртиптә карап тикшерелә.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

дәүләт хезмәтеннән файдаланучының законлы вәкиле яисә вәкаләтле заты буларак эш итүче гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла.

Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткән вакытта әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, белгеч гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны аңа кире кайтара. Гариза бирүче таләбе буенча баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә Эш башкару бүлеге белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма рәвештә аңлатып, документларны аңа почта (электрон почта) аша кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм терки;

документлар кабул итү көне һәм вакыты, бирелгән керү номеры турында билге куеп, хәбәрнамәнең күчермәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыра яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) тапшыра;

гаризаны Татарстан Республикасы мәдәният министрына (алга таба – Министр) электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша җибәрә.

Гаризалар ял (бәйрәм) көннәрендә электрон формада кергән очраклардан тыш, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне башкарыла,

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Министрга юлланган гариза.

3.3.3. Министр гаризаны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен Министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карап тикшерә һәм аны карап тикшерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгечен) билгели һәм аңа гаризаны башкару өчен тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә башкару өчен җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запрослар төзү һәм аларны дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) тапшырмаган очракта, Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар законнарда билгеләнгән вакыт эчендә әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) тапшыралар.

Процедураның нәтиҗәсе: запросларга җаваплар яки белешмәләр (документлар) булмау турында хәбәрнамәләр.

3.4.3. Министрлыкка бәяләмә бирү турында гариза килгән очракта һәм шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү берничә башкарма хакимият органы тарафыннан, шул исәптән Министрлык тарафыннан башкарыла икән, бәяләмә Министрлык тарафыннан бирелә. Кирәк булганда Министрлык башка кызыксынган органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр соратып ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза Бүлек белгеченә башкару өчен килгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: запрослар төзү һәм җибәрү, ведомствоара запроска җавап итеп, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка оешмалардан алар карамагында булган белешмәләрнең килүе.

3.5. Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилле хәбәрнамә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү.

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 - 3.4.3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр нигезендә һәм гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә теркәү хаты проектларын, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын әзерли һәм аларны килештерү өчен Идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура запросларга җаваплар килгән көннән алып бер эш көне эчендә, әмма бәяләмә бирүнең (бәяләмә бирүдән баш тарту) әлеге Регламентта билгеләнгән вакыты тәмамланганчы биш эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән теркәү хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.2. Бүлек башлыгы теркәү хатын, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын тикшерә һәм аларны Министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар Бүлек башлыгына килештерүгә кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына килештерү өчен җибәрелгән теркәү хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.3. Министрның беренче урынбасары теркәү хатын, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерә һәм аларны Министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар Министрның беренче урынбасарына килештерүгә кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Министрга карап тикшерүгә җибәрелгән теркәү хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.4. Министр бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән теркәү хатын имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министр тарафыннан имзаланган һәм Эш башкару бүлегенә теркәүгә җибәрелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән теркәү хаты.

3.5.5. Эш башкару бүлеге белгече:

теркәү хатын, бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне терки;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) имзаланган бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура башкарыла:

бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) почта аша җибәргәндә – Министр бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) шәхсән алу күрсәтелгәндә – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) бирү (җибәрү).

3.6. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гаризаны карап тикшерү.

Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән гариза әлеге Регламентның 3.3 - 3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карап тикшерелә.

3.7. Техник хатаны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү элек бирелгән бәяләмәдә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәдә җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язуларны, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне яңадан рәсмиләштерү әлеге Регламентның 4 номерлы кушымтасындагы форма буенча төзелгән, техник хатаны төзәтү турындагы теркәлгән гариза (алга таба – гариза) нигезендә башкарыла. Гариза әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсен файдаланып тапшырыла. Гаризага теркәп гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә, шулай ук, документлар гариза бирүче исеменнән тапшырылса, гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкару өчен кирәкле, гариза бирүче вәкиле вәкаләтләрен раслаучы ышанычнамә бирелә.

3.7.1. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм терки;

Министрга электрон документ әйләнеше аша электрон формадагы гаризаны җибәрә.

Гариза ял (бәйрәм) көннәрендә кергән очраклардан тыш, әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Министрга юлланган гариза.

3.7.2. Министр гаризаны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен Министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасарына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Министрның беренче урынбасары гаризаны карап тикшерә һәм аны карап тикшерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм аңа башкару өчен гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә башкару өчен җибәрелгән гариза.

3.7.5. Бүлек белгече:

теркәү хатын, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын әзерли;

теркәү хатын, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектын Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза Бүлек белгеченә җибәрелгән көннән алып ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килешетерүгә җибәрелгән теркәү хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.7.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән теркәү хатының, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектының дөреслеген тикшерә, аны килештерә һәм Министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура теркәү хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты Бүлек белгеченнән килештерү өчен килгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм Министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрелгән теркәү хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проекты.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары теркәү хатын, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерә һәм аларны Министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура теркәү хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән

хәбәрнамә проектлары Бүлек башлыгыннан килгән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм Министрга карап тикшерүгә җибәрелгән теркәү хаты, яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.7.8. Министр яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән теркәү хатын имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министр тарафыннан имзаланган һәм Эш башкару бүлегенә теркәүгә җибәрелгән яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән теркәү хаты.

3.7.9. Эш башкару бүлеге белгече:

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән теркәү хатын терки;

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура башкарыла:

яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) почта аша җибәргәндә – бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) Министр имзалаган көннән соң бер эш көне эчендә;

гаризада яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) шәхсән алу ысулы күрсәтелгән булса – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә).

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлыкның вазифаи затлары тарафыннан әлеге Регламентның һәм башка норматив хокукый актларның дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту әлеге административ процедураны башкару өчен җаваплы зат һәм Министрның дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы беренче урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы контроль Министрлыкның вазифаи затлары тарафыннан әлеге Регламентның һәм башка норматив хокукый актларның дәүләт хезмәтен күрсәтүгә

таләпләрне билгели торган нигезләмәләрен үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять язылган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләрне тикшерү тора:

эш башкаруны алып бару;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүен;

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү вакытын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы характерда (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш характерда (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элегрәк ачыкланган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Регламент һәм башка норматив хокукый актлар таләпләрен бозуларны бетерүне тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затларның үз хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазифаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгатьләре.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылганлыгы ачыкланган очракта дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип табылган вазифаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазифаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр Министрлыкка шикаять бирү хокукына ия. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә Министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүнең билгеләнгән вакытын бозу;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, аның вазифаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда үзләре җибәргән ялгыш һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яисә тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүне

яки дәүләт хезмәте күрсәтүне беренче тапкыр кире какканда аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язма формада кәгазь чыганакта яки электрон формада бирелә.

Министрлыкның, Министрлыктагы вазифаи затның, Министрлыктагы дәүләт хезмәткәренең, Министрның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтын, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталын файдаланып, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган Министрлык, Министрлыкның вазифаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) гариза бирүче Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвенә нигез булган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны теркәгән көннән алып 15 эш көне эчендә. Министрлык, Министрлыкның вазифаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы дәгъваланган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләтү каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә шикаять канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7.1. Шикаятьне канәгатьләндерү тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатыннан Министрлык тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте алу өчен башкару кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7.2. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә юллана торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазифаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче номерлы кушымта

(форма)

Татарстан Республикасы
мәдәният министрына
________________________
______________________________________
оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы, телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан

______________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерцияле оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры)

күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең
______________________________________________________________________
(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында»гы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеге нигезендә иҗтимагый файдалы хезмәтнең исеме, күрсәтелә торган хезмәтнең атамасын сайлау:
инвалидларга социомәдәни реабилитацияләү яки абилитацияләү уздыру;
мәдәни-массакүләм чаралар оештыру һәм уздыру;
спектакльләр (театраль постановкалар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру);
концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру);
сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыру;
2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә эшләүче оешмалар күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон нигезендә оешма-оператор тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, мәдәният оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты турында мәгълүматны җыю, гомумиләштерү һәм анализлау буенча күрсәтелә торган хезмәтләр (мәдәният өлкәсендәге оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтнең сыйфатын бәйсез бәяләү системасын

популярлаштыру һәм анда күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдаланучыларның катнашу мөмкинлеге, гражданнарны бәйсез бәяләүгә җәлеп итү өлешендә);
массакүләм мәдәни чаралар (лекторийлар, семинарлар, фестивальләр, мәдәни-агарту проектлары) оештыру һәм үткәрү;
музей экспозицияләрен (күргәзмәләрен) булдыру, күчмә күргәзмәләр оештыру;
спектакльләр оештыру;
концертлар һәм концерт программалары оештыру;
өстәмә белем бирү өлкәсендә Россия Федерациясе халыкларының үзенчәлеген, мәдәниятен, телләрен һәм традицияләрен саклау һәм яклау бурычларын хәл итүне тәэмин итә торган хезмәтләр күрсәтү (гражданнарны Россия Федерациясендә яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм традицияләре белән таныштыру);
нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру;
телепрограммалар җитештерү һәм тарату;
радиопрограммалар җитештерү һәм тарату;
аудиовизуаль музыкаль һәм мәдәни-агарту программалары җитештерү һәм тарату;
экскурсия программалары оештыру)

сыйфаты аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Оешманың чит ил агенты функциясен үтәүче коммерцияле булмаган оешма түгеллеген һәм бер ел һәм аннан күбрәк вакыт эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында»гы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган, аталган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күсәтүен раслыйбыз»:

____________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең, аның эчтәлегенә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау (хезмәт күрсәтүнең күләме, сроклары, сыйфаты);

____________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт башкаруда турыдан-туры катнаша торган затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) тиешле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белем бирү, тиешле өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуын, шундый затларның саны җитәрлек булуын раслау)

____________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрдән файдаланучыларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлеген раслау (оешмаларның үзләре тарафыннан суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, үз компетенцияләре нигезендә башка органнар тарафыннан нигезле дип табылган, иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм (яки) карарларына карата бәяләмә бирер алдыннан узган ике ел дәвамында шикаятьләр булмау)

____________________________________________________________

(коммерцияле булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

(бәяләмә бирер алдыннан ике ел дәвамында оешманың 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавын раслау)

Раслый торган документлар теркәлә:

1. ____________________
2. ____________________
3. ____________________

һәм башкалар.

(Вазифасы) (Имза) (Ф.И.А.)

"____"____________20_ел

М.У. (булган очракта)

Социаль юнәлешле коммерцияле
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый
файдалы хезмәтләр сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры
килүе турында бәяләмәләр бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче номерлы кушымта

(форма)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында
БӘЯЛӘМӘ

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешманың

______________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерцияле оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры)

_____________________ эчендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында»гы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүен раслый:

______________________________________________________________________________;
(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең исемнәре)

______________________________________________________________________________;

Министр

М.У.

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче номерлы кушымта

(форма)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең билгеләнгән критерийларга
туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында
дәлилләнгән хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма:

______________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерцияле оешманың тулы исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры)

тарафыннан күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтнең:

______________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт атамасы)

сыйфаты тиешле критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәт иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килми:

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________;

______________________________________________________________________

(критерийларга туры килмәү күрсәтелә)

Министр

М.У.

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче номерлы кушымта

(форма)

Татарстан Республикасы
мәдәният министрына
_______________________
_____________________________________
оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы, телефон номеры (булган очракта)

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

_____________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың исеме)

социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә яки социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килү турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итә.

______________________________________________________________ күрсәтелгән:
(бирелгән документ)

___________________________________________________________________________,

Дөрес белешмәләр: __________________________________________________,

Ясалган техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйбыз.

Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелә торган үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) түбәндәге ысул белән бирүегезне сорыйбыз:

___________________________________________________________________________
(шәхсән, почта аша)

Түбәндәге документларны теркибез:
1.
2.

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
(Вазифасы) (Имза) (Ф.И.А.)

"____"____________20_ел

М.У. (булган очракта)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

| Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | (843) 264-74-01 | mkrt@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | (843) 264-74-09 | Yuliya.Adgamova@tatar.ru |
| Контроль һәм эш башкару бүлеге башлыгы | (843) 264-75-06 | Liliya.Zainullina@tatar.ru |
| Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы | (843) 264-74-38 | Ayrat.Fayzrahmanov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Адресы | Вазифасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| 420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1 йорт | Татарстан Республикасы халыклары мәдәниятен һәм телләрен үстерү идарәсе башлыгы | (843) 264-76-19 | Lyaysan.Nizamova@tatar.ru |